**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«28» ноябрь 2025ел** **№ 156**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 сентябрендәге 529 номерлы «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе»нең 2025 елның 28 октябрендәге 150-25-ИН номерлы хатын карап, «Теләче муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 26 сентябрендәге 763 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган,Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына 2 номерлы кушымтага үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 сентябрендәге 529 номерлы «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (31.01.2018 № 62, 27.10.2020 № 461, 08.10.2022 № 194, 27.05.2024 № 71, 22.11.2024 № 148 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә:

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Теләче муниципаль районы Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи окладның күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 33 345 |
| 2. | Оператив дежур | 25 650» |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары – территориаль үсеш бүлеге башлыгы Р.В. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин